Әхлак

# АЛЛАҺ, КОРЪӘН ҺӘМ ПӘЙГАМБӘР БЕЛӘН

## ШАЯРУ - КӨФЕРЛЕК




Аллаһы Тәгалә һәм Аның рәсүле, дин, Коръәне белән шаяру һәм аларны мәсхәрәләп көлү иманны, тәүхидне юк итә. Аллаһы Тәгалә әйткән: "Әгәр син алардан Аллаһы Тәгаләне һәм Аның аятьләрен кимсетеп сөйләшеп торган чакларында "Ни сөйлисез?" дип сорасаң, алар: "Үз-ара уйнап сөйләшәбез" дип әйтерләр. Син аларга: "Сез Аллаһы Тәгалә һәм Аның аятьләрен һәм Аның рәсүлен мәсхәрә кыла түгел идегезме?" дип әйт". ("Тәүбә": 65) Шуннан соң монафыйклар гозер күрсәтеп, рәсүлүллаһтан гафу сорарга килделәр. Пәйгам-бәребез (с.г.в.с.) аларга әйтте: "Гозер күрсәтмәгез, иман китереп мөселман булганнан соң Аллаһыга каршы барып, дин-нән көлеп кяфер булдыгыз".

Бу аятьтән без диннән көлүчеләр алар монафыйклар икәнен белдек. Ләкин бу аятьтә "гозер күрсәтмәгез, ягъни гафу үтенеп тормагыз, иман китереп мөселман булганыгыздан соң Аллаһыга каршы барып кяфер булдыгыз инде" дигән сүзне ничек аңларга соң? Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) монафыйкларның барысын да белгән. Әгәр улар үлеп китсәләр аларның җеназаларын да укымаган.

Бу аятьтә Пәйгамбәребез янына гозер сорап килгән кешеләр, алар чын монафыйклар. Шуңа күрә Пәйгамбәребез аларга "гозер күрсәтеп тормагыз, сез барыбер кяферләр" дип әйткән. Әмма бүгенге көндә берәү белмичә хаталанып андый эшләрне эшләсә һәм соңыннан тәүбә кылса аңарга без дөрес эшлисең, әгәр тәүбә кылсаң Аллаһы Тәгалә синең гөнаһларыңны кичерә, дип хупларга тиешбез, чөнки Аллаһы Тәгалә ширектән кала бөтен гөнаһларны кичерүче зат. Без кешеләрнең калебләрендә нәрсә бар икәнен белмибез бит. Шуңа күрә асыл кагыйдәгә кайтабыз, ә асыл кагыйдә безгә "кем гөнаһларыннан тәүбә кылса, аны Аллаһы Тәгалә теләсә кичерә" ди. Бу аятьтән без шаяру һәм мәсхәрәләү хәрам һәм диннән чыгара икәнен белдек. Мәсәлән, әгәр берәү икенче мөселманның сакалына карап, "Нәрсә син көрәк кадәрле сакал җибәреп йөрисең, син бит болай попларга охшыйсың" дип мөселманнан мәсхәрәләп көлсә ул кеше кяфер була, чөнки ул мөселманның үзеннән көлмәде "син надан, көчсез, зиһенсез акылсыз" димәде, ә ул аның сакалыннан көлде, сакал бит ул Пәйгамбәребезнең әмере, ә аның әмере - шәригать, шәригатьтән көлүче кяфер, тәүбә кылмыйча үлеп китсә җәһәннәмле булачак.

"Тәбүк сугышында бер кеше иптәшләренә: "Бу Коръән укучы кешеләр кебек кешеләрне күргәнебез булмады. Алар корсакларын тутырып ашарга теләүчеләрнең теләүчеләре, ялган сөйләүчеләрнең сөйләүчеләре, дошманнар белән очрашканда куркакларның куркагы", - дип әйтте. Ул бу сүзе белән Пәйгамбәребезне (с.г.с.) һәм аның сахабәләренә ишарәләп, төрттереп әйтте. (Ләкин аның сүзләре барысы да хата һәм ялган, чөнки Пәйгамбәребез (с.г.с.) һәм аның сахабәләре бик аз ашыйлар, бик дөрес сөйлиләр һәм бер дә курыкмыйча батырларча сугышалар иде). Ул кешенең сүзләрен ишетүче Гауф бине Мәлик: "Ялганладың, сүзләрең дөрес түгел, дөреслектә син Пәйгамбәребезне (с.г.с.) һәм сәхабәләрне мәсхәрәләп монафыйк булдың. Син монафыйксың, мин бу сүзләреңне Пәйгамбәребезгә (с.г.с.) хәбәр итәм", - диде һәм Пәйгамбәребез (с.г.с.) янына хәбәр бирер өчен китте. Килеп җиткәч аны Коръән узганын аңлап алды, ягъни Аллаһы Тәгалә монафыйкларның Аллаһ диненнән һәм Пәйгамбәребездән (с.г.с.) һәм аның сахабәләреннән көлүләре, мәсхәрәләре хакында ирештергән икәнен сиздe. Чөнки Пәйгамбәребез (с.г.с.) янына бая көлеп мәсхәрәләп сөйләүче кеше килгән, ә Пәйгамбәребез (с.г.с.) дөясенә иярен һәм кирәкле нәрсәләрен куеп, менеп атланган, ә теге кеше Мөхәммәдтән (с.г.с.).

"Әй Аллаһының илчесе, дөреслектә без юл мәшәкатьләрен җиңеләйтер өчен атланып йөргәндәге шаярып мәзәк кыла торган сүзләр генә сөйләдек, башка һичнәрсә сөйләмәдек, дип Пәйгамбәребезгә әйткәнен күрә. Әмма Ибне Гомәр: "Мин ул монафыйкның Пәйгамбәребезнең (с.г.с.) дөясенең йөгәненә ябышканын, аның аякларын ике яклап ташлар кысып авыртырганын һәм ул: "Дөреслектә без шаярдык һәм уйнадык, ягъни шаярып һәм уйнап кына мәзәк кылып сөйләштек", дип әйткәнен һәм аңа Пәйгамбәребез (с.г.с.): "Сез Аллаһы Тәгалә һәм Аның аятьләрен һәм Аның рәсүлен мәсхәрә кыла түгел идегезме, гозер күрсәтмәгез, иман китереп мөселман булганыгыздан соң Аллаһыга каршы барып диннән көлеп кяфер булдыгыз", дип әйткәнен һәм Пәйгамбәребез (с.г.с.) аңарга әйләнеп тә карамады һәм гозерен дә кабул итмәде. Ошбу аятьне арттырмыйча укып бирде дә, башка бернәрсә дә әйтмәгәнен күрдем", дип риваять кылды".

Аллаһының диненнән көлүченең хөкеме - кяфер. Ул кешенең урыны мәңгелек җәһәннәм. Әгәр инде чын күңеленнән тәүбә итсә, Аллаһы Тәгалә аны кичерүе мөмкин.

Кәүсәрия ШАФИКОВА
шагыйрә

* * *

*Кеше туган чагын белми,*
*Үлгәнен дә белмидер.*
*Яшәгәндә белми генә*
*Еламыйдыр, көлмидер.*

*Белеп яши, шатлык - татлы,*
*Кайгы - ачы булганын.*
*Белә, авырлыклар белән*
*Көрәшергә туганын.*

*Көрәшә ул җилләр белән,*
*Давылдан да курыкмый.*
*Белеп тора, кыенлыклар*
*Аны аяктан екмый.*

*Белә, шушы җир йөзендә*
*Югалту бар, табыш бар.*
*Үкендерер ялгышлар бар,*
*Изгелек бар, каргыш бар.*

*Белгәнемне, күргәнемне,*
*Мин дә өйдем тау итеп.*
*Дөньяга килгәнне белмим,*
*Шулай гына, иман белән*
*Булсын иде дим китеп.*

### ЯҢГЫР КӨТКӘНДӘ

*Яңгырсыз җәй, куырасың,*
*Кызган табаңа салып.*
*Игеннәр уңыш бирерме,*
*Эссеңнән исән калып?*

*Тилмереп яңгыр көтәләр,*
*Хәлдән тайган тамырлар.*
*Болын тулы гүзәл гөлләр*
*Ничек исән калырлар!*

*Бар тирә-як сары көя,*
*Табигать ут эчендә.*
*Җәй, димәк, шушындый ямьсез*
*Була аласың син дә!*

*Бар да бәхет көткән кебек,*
*Туфрак та яңгыр көтә.*
*Мин шатланып яңа җырлар*
*Иҗат итәр идем, әгәр,*
*Болыт күренсә күктә!*

* * *

*Кайгы килсә - сабырлык бар,*
*Һәр чир әҗәлең түгел.*
*"Көч җитәрлек" - дигән сүзгә*
*Ышанып куя күңел.*

*Аккан суны туктаталар,*
*Сүндерәләр утын да.*
*Тик йөгәнләп алыр өчен,*
*Җилләрдән дә җитез гомер*
*Бирми бер минутын да.*

### САБЫРЛЫК

*Боегып калсам, борчылма,*
*Андый хәлем күпкә түгел.*
*Елмаерга көч табармын,*
*Айдай, кояштай ул күңел.*

*Күзләремнең яшен күрсәң,*
*Күрмәмеш бул, шулай кирәк.*
*Тешләремне нык кысканмын,*
*Еласам да, елыйм сирәк.*

*Минем балкып торган чагым -*
*Сер бирмәвем авырлыкка.*
*Бел, әнкәйсез калу белән,*
*Таяндым мин сабырлыкка.*

### КАЙТАЧАКМЫН

*Кош буласым килә, туган ягым*
*Талларына кайтып кунар өчен.*
*Шатлык - куанычлар белән генә*
*Сайрар өчен шунда иртә кичен.*

*Көмеш сулы инеш кенә булып*
*Агар илем туган яккаема.*
*Рәхәт булыр иде кайткан кебек,*
*Иң бәхетле бала чаккаема.*

*Юк ла инде, болар хыял гына,*
*Туган якка ләкин, кайтачакмын.*
*Алганнан соң соңгы сулышымны,*
*Газиз туфрагыма ятачакмын.*

### КОЛЯСКАМДА БАРАМ

*Тәгәрмәчләр тәгәриләр,*
*Кар шыгырдап сер сөйли.*
*Тукта-тукта, сер сөйләми,*
*Кар шыгырдап җыр көйли.*

*Минем яңа җырым ич бу,*
*Аклык, шатлык турында.*
*Бәхетеннән ташып чыккан*
*Сөю, сафлык турында.*

*Килер язлар турында җыр,*
*Анда кошлар тавышы.*
*Анда ялкын ялмап алган*
*Йөрәкләрнең кагышы.*

*Тәгәрмәчләр карлы юлда,*
*Юк, мин иген кырында.*
*Тыңламыйм кар шыгырдавын,*
*Башаклар шавын ишетәм,*
*Туып килгән җырымда.*

# КЕМГӘ НАДАН ДИП ӘЙТЕЛӘ?

Рагыйб әл-Исфәхани надан мәгънәсенә килә торган "җәһл" сүзен өч төрле ачыклый.

Беренчесе, нәфеснең белемсез булуы; икенчесе, чын хакыйкатьтән башка бер нәрсәгә ышану; өченчесе, бер мәсьәләдә эшләнергә тиеш булган нәрсәнең киресенчәсен эшләү.

Надан дип белемнән мәхрүм булган, җитди хәрәкәт кыла алмаган һәм үзен танымаган кешеләргә әйтелә. Ислам диненнән алда булган заманга җаһилият дип әйтелә, һәм җаһили хәрәкәтләр һәр дәвердә һәм бөтен җирдә күренергә мөмкин. Хз. Билалга "кара хатынның улы" дип әйтү белән кимсеткән Хз. Әбү Зәрргә пәйгамбәр Әфәндебез (с.г.в.) шулай диде: "Аны әнисенең төсе аркасында хурлыйсыңмы, димәк, синдә җаһилият әхлагыннан бер өлеш әле дә бар". (Бохари, иман, 22). Янә Аллаһның Рәсүле (с.г.в.) "Җаһилият дәвам иттерүчеләр бездән түгел", - дип әйтә (Мөслим). Башка бер хәдистә шулай ди: "Өммәтем арасында җаһилият дәвереннән калган һәм бөтен яклап ташлый алмаячак дүрт нәрсәләре бар: нәселлек белән мактану, башкаларның нәсел-нәсеп юлларына тел сузу, йолдызлар сәбәпле яңгыр сорау, вафат булган кеше өчен кычкырып елау" (Мөслим).